УДК УДК 81'354

***Ю. Хисияма***

# СОҢГЫ ИҖЕКТӘ [И] СУЗЫГЫ БУЛГАН ГАРӘП-ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫНДА СИНГАРМОНИЗМ КҮРЕНЕШЕ:

## Татар теленең язма корпусы нигезендә тикшеренүләр

Татарский язык подчиняется закону сингармонизма, который в некоторых заимствованных словах иногда нарушается. В данном исследовании мы использовали Письменный корпус татарского языка для изучения колебаний, наблюдаемых в аффиксальных гласных арабо-персидских заимствований, имеющих [и] в конечном слоге, и выяснили следующее: 1) слова с гласным заднего ряда в предпоследнем слоге часто имеют гласные заднего ряда в аффиксах, но когда конечный согласный звук слова является передним согласным [л], аффиксы часто имеют гласные переднего ряда; 2) слова с гласным переднего ряда в предпоследнем слоге часто имеют гласные переднего ряда и в аффиксах, но когда конечный согласный звук слова является задним согласным [к] или [х], суффиксы часто имеют гласные заднего ряда. Основываясь на результатах исследования, мы утверждаем, что в данном типе заимствований гласный предпоследнего слога и конечный согласный слова участвуют в сингармонизме, в то время как гласный конечного слога [и] участвует в нем в меньшей степени.

**Ключевые слова**: татарский язык, закон сингармонизма, заимствование, орфография, корпус.

The Tatar language obeys the law of synharmonism, which is sometimes violated in some borrowed words. In this work we used The written corpus of the Tatar language to study the fluctuations seen in the affixal vowels of Arabic-Persian loanwords that have [и] (i) in the final syllable and found the following: 1) words with a back vowel in the second to the last syllable often have back vowels in their suffixes but when the final consonant is the front consonant [л] (l), suffixes often have front vowels; 2) words with a front vowel in the second to the last syllable often have front vowels in their suffixes but when the final consonant is the back consonant [к] (q) or x (x), suffixes often have back vowels. Based on the survey results we claim that in this type of loanwords the second to the last syllable vowel and word-final consonant are involved in vowel harmony, while the final syllable vowel [и] (i) is less involved in it.

**Keywords:** Tatar language, vowel harmony, loanword, orthography, corpus.

Сөйләм агышында янәшә урнашкан авазлар бер-берсе тәэсирендә төрле үзгәрешләр кичерергә мөмкин. Татар телендә шундый үзгәрешләрнең берсе – сингармонизм. Ул – сузыклар ассимиляциясенең бер төре. «Сингармонизм, яки сузыклар гармониясе – барлык төрки телләр өчен дә диярлек (чуваш һәм үзбәк телләреннән башка) характерлы билге» [1: 31]. Сингармонизмның ике төре бар – рәт гармониясе һәм ирен гармониясе. Язуда бары рәт гармониясе генә чагылыш

таба. Рәт гармониясе булганда, сүздә я алгы рәт (нечкә) сузыклары [ә], [э], [ө], [ү], [и], я арткы рәт (калын) сузыклары [а], [ы], [о], [у] гына кулланыла: *кеше-ләр-гә, атлы-лар-га*.

Кайбер алынма сүзләр бу законга буйсынмый [1: 32; 6: 903; 5: 11]. Мәсәлән, соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларына калын кушымчалар ялгана ала: *шаһит-лар*. Бу турыда тәфсилләп язылган хезмәтләр юк диярлек. Инглиз телендә язылган татар теле грамматикасында кайбер гарәп-фарсы алынмаларына, соңгы иҗектә нечкә сузык булса да, калын кушымчалар ялгана (боларның күбесе беренче иҗектә – [а], икенче иҗектә [и] сузыгы булган ике иҗекле алынмалар) дип аңлатыла: *тарих-**ның*** [5: 11].

Ләкин, язма материалларда күзәтелгәнчә, әлеге алынмаларга калын кушымчалар да, нечкә кушымчалар да ялгана ала: *шаһит-лар* ~ *шаһит-ләр* [3]. Өч һәм күбрәк иҗекле сүзләрдә дә шуны ук күзәтәбез: *Мәрҗани-г**а*** ~ *Мәрҗани-г**ә*** [3]. Гарәп-фарсы алынмалары тарихи-традицион принципка нигезләнеп язылса да, кушымчаның язылышы күпмедер дәрәҗәдә әйтелешне чагылдыра. Бу мәкаләдә без соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларында сингармонизм күренешләрен Татар теленең язма корпусы нигезендә, анда теркәлгән материалларны кулланып тикшердек.

Соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларын җыйганда, «Татар телендәге гарәп-фарсы алынмалары» сайтыннан [2] файдаландык. Кеше исемнәрен дә исәпкә алдык. Дүрт яки күбрәк иҗекле сүзләр бик сирәк булганга, ике яки өч иҗекле сүзләр тикшерелде.

Хәзерге вакытта Татар теленең язма корпусы 500 миллионнан артык сүзне колачлый, төрле сүзформаларның саны 5 миллион тирәсе. Теркәлгән текстлар, нигездә, өч стильгә – публицистика (аларның күләме ≈ 60%), сәнгатьле чәчмә әдәбият (≈ 35%) һәм гуманитар юнәлештәге фәнни стильгә (≈ 5%) карый [3].

Шушы корпустан файдаланып, соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларында сингармонизм күренешләрен түбәндәге адымнар белән тикшердек. Башта, беренче таблицаның сул баганасында күрсәтелгәнчә, сүз һәм тамгаларны җыеп (сүз + кушымча + йолдызчык), «Табу!» төймәсенә бастык (1 нче рәсем). Беренче таблицаның сул баганасында «шаһит» сүзен тикшерү мисалга алынды. Йолдызчык – 1 яки аннан күбрәк сүз формасы була алуны күрсәтә. Шуңа күрә, «шаһитлар*» дип кертеп, «Табу!» төймәсенә баскач, «шаһитлар, шаһитлары, шаһитларыннан» кебек сүз формалары табыла (2 нче таблица).

Искәрмә: *и* хәрефенә беткән сүзләргә ялганган *е* хәрефенең калын сузыкны [йы] яки нечкә сузыкны [йэ] белдерүе билгеле булмагач, *и* хәрефенә беткән сүзләрнең 1 нче таблицаның икенче рәтендәге формалары тикшерелмәде. Мәсәлән, *рухание* формасының [руханийы] яки [руханийэ] дип әйтелүе билгеле түгел.




1 нче рәсем. Корпус экраны




2 нче рәсем. Корпус экраны

1 нче таблица

Эзләү ысулы

| Сүзләр һәм тамгалар | Табылачак сүз формалары | Табылган сүзләр |
|---|---|---|
| шаһитлар*<br>шаһитләр* | исем + күплек (+ тартым)<br>(+ килеш, һ. б.) | шаһитләреннән,<br>шаһитлар һ. б. |
| шаһиты*<br>шаһите* | исем + тартым (+ килеш, һ. б.) | шаһитыбыз,<br>шаһитеңә һ. б. |
| шаһитны*<br>шаһитне* | исем + төшем яки иялек килеше<br>исем + -ныкы/-неке | шаһитны,<br>шаһитнең һ. б. |
| шаһитта*<br>шаһиттә* | исем + урын яки чыгыш килеше<br>исем + -дай/-дәй/-тай/-тәй | шаһитта,<br>шаһиттән һ. б. |
| шаһитка<br>шаһиткә | исем + юнәлеш килеше | шаһитка,<br>шаһиткә һ. б. |

Алдагы этапта корпустан табылган мисалларның санын, аларга калын һәм нечкә кушымча ялгануга карап, ике төркемгә бүлеп исәпләдек. 2 нче таблицада «шаһит» сүзен тикшерү нәтиҗәсе күрсәтелгән. Күренгәнчә, «шаһит» сүзенә калын кушымчалар күбрәк ялгана (70,3%).

2 нче таблица

Исәпләү үрнәге

| | Сүзләр һәм корпуста табылган мисаллар саны | | | | | Барлыгы (нисбәте) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Калын кушымча | шаһитлар*<br>5,862 | шаһиты*<br>4,170 | шаһитны*<br>153 | шаһитта*<br>68 | шаһитка<br>65 | 10,318<br>(70,3%) |
| Нечкә кушымча | шаһитләр*<br>3,148 | шаһите*<br>1,073 | шаһитне*<br>80 | шаһиттә*<br>16 | шаһиткә<br>33 | 4,350<br>(29,7%) |

Ике иҗекле сүзләргә күз салыйк. Беренче иҗектә калын сузык булган сүзләрне тикшерү нәтиҗәләре – 3 нче таблицада, беренче иҗектә нечкә сузык булган сүзләрне тикшерү нәтиҗәләре 4 нче таблицада күрсәтелде (һәр таблицада табылган мисалларның беренче унлыгы урнаштырылды).

3 нче таблица

Беренче иҗектә калын сузык хәрефе булган ике иҗекле сүзләр

| | Кушымча | | Нисбәте (калын) |
|---|---|---|---|
| | калын | нечкә | |
| тарих | 240,413 | 161 | 99,9 |
| табиб | 87,350 | 1,005 | 98,9 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| тасвир | 2,590 | 34 | 98,7 |
| шаһит | 10,318 | 4,350 | 70,3 |
| залим | 296 | 1496 | 16,5 |
| мохит | 3,293 | 30,236 | 9,8 |
| Камил | 162 | 3,374 | 4,8 |
| Наил | 44 | 2,608 | 1,7 |
| хаким | 36 | 7,179 | 0,5 |
| галим | 173 | 115,112 | 0,2 |

4 нче таблица

Беренче иҗектә нечкә сузык булган ике иҗекле сүзләр

| | кушымча | | Нисбәте (калын) |
|---|---|---|---|
| | калын | нечкә | |
| Тәуфикъ | 285 | 5 | 98,3 |
| мәшрикъ | 160 | 53 | 75,1 |
| тәсбих | 415 | 541 | 43,4 |
| Мәсих | 29 | 1032 | 2,7 |
| Фәнис | 2 | 1911 | 0,1 |
| дәлил | 12 | 15,733 | 0,1 |
| тәэсир | 11 | 31,055 | 0,0 |
| хәдис | 3 | 12,762 | 0,0 |
| тәкъдим | 4 | 57,337 | 0,0 |
| тәртип | 5 | 103,524 | 0,0 |

Таблицалардан аңлашылганча, 1) беренче иҗектә калын сузык булган сүзләргә, нигездә, калын кушымчалар күбрәк ялгана: *табиб-лар*. Ләкин сүз азагында *л* яки *м* хәрефе булган очракта, нечкә кушымчалар күбрәк ялгана: *Наи**л**-гә, гали**м**-нәр*; 2) беренче иҗектә нечкә сузык булган сүзләргә, нигездә, нечкә кушымчалар күбрәк ялгана: *тәртип-ләр*. Ләкин сүз азагында [к] яки [х] тартыклары булган очракта, калын кушымчалар күбрәк ялгана: *Тәуфи**къ**-лар*, *тәсби**х**-лар*.

Бу тенденцияләрдән чыгармалар да бар. Мәсәлән, *Һашим* сүзе *м* хәрефенә беткән булса да, аңа күбрәк калын кушымчалар ялгана (99,8%).

Өч иҗекле сүзләргә күз салыйк. Тикшерү нәтиҗәләре 5 нче таблицада күрсәтелде.

5 нче таблица

Өч иҗекле сүзләр

| | Кушымча | | Нисбәте (калын) |
|---|---|---|---|
| | калын | нечкә | |
| монафикъ | 1,278 | 0 | 100,0 |
| рухани | 7,225 | 123 | 98,3 |
| Насыйри | 2,923 | 101 | 96,7 |
| Максуди | 2,124 | 142 | 93,7 |
| Ибраһим | 2,512 | 209 | 92,3 |
| Газраил | 147 | 856 | 14,7 |
| Фәләстин | 50 | 447 | 10,1 |
| Фидаил | 25 | 287 | 8,0 |
| Мәрҗани | 444 | 5,189 | 7,9 |
| Фәхретдин | 67 | 2,138 | 3,0 |
| мәгариф | 263 | 30,640 | 0,9 |
| мөгаллим | 6 | 19,266 | 0,0 |
| гаскәри | 0 | 2,700 | 0,0 |
| мөхәррир | 0 | 30,506 | 0,0 |

Таблицадан аңлашылганча, 1) соңгыдан алдагы иҗектә калын сузык булган сүзләргә, нигездә, калын кушымчалар күбрәк ялгана: *Насыйри-**ның***. Ләкин сүз азагында [л] тартыгы булган очракта, нечкә кушымчалар күбрәк ялгана: *Газраил-**не***; 2) соңгыдан алдагы иҗектә нечкә сузык хәрефе булган сүзләргә, нигездә, нечкә кушымчалар күбрәк ялгана: *гаскәри-**ләр***.

Шуны искәртеп үтәргә кирәк: *мәгариф* һәм *мөгаллим* сүзләренең икенче иҗеге *га* дип язылса да, [ғә] дип әйтелә. *Мәрҗани* сүзенең икенче иҗеге *җа* дип язылса да күп очракта *җә* дип әйтелә. Шуңа күрә, аларга күбрәк нечкә кушымчалар ялгана.

Тикшеренү нәтиҗәләренә һәм саф татар сүзләрендә [и] сузыгының нигездә беренче иҗектә генә әйтелүенә таянып [1: 24; 5: 10], без түбәндәге нәтиҗәгә киләбез: 1) әлеге алынмаларның соңгы иҗегендәге [и] сузыгы сүзгә кушымча ялгануда артык зур роль уйнамый; 2) соңгыдан алдагы иҗектәге сузык һәм сүз азагындагы тартык тиешле кушымча сайлауга тәэсир итә.

Соңгыдан алдагы иҗектә калын сузык булган сүзләргә, нигездә, калын кушымчалар күбрәк ялгану, һәм соңгыдан алдагы иҗектә нечкә сузык булган сүзләргә, нигездә, нечкә кушымчалар күбрәк ялгану әлеге алынмаларда соңгыдан алдагы иҗектәге сузыкның да, соңгы иҗектәге [и] сузыгының да ялганасы кушымчаны сайлауда мөһим булуын аңлата.

Соңгыдан алдагы иҗектә калын сузык булган сүзләрдә сүз азагындагы тартык [л] (ике иҗекле сүзләрдә [л] яки [м]) булган очракта, нечкә кушымчалар күбрәк ялгану әлеге алынмаларда [и] сузыгыннан һәм авызның алгы өлешендә әйтелә торган сонор тартыктан торган соңгы иҗекнең сингармонизмда «нечкә иҗек» булып эшләвен, ягъни сүз азагындагы тартыкның да сингармонизмда катнашуын аңлата. Аеруча [л'] авазының палаталь варианты сингармонизмда зур роль уйный.

Соңгыдан алдагы иҗектә нечкә сузык булган сүзләрдә, сүз азагындагы тартык [қ] яки [х] булган очракта, калын кушымчалар күбрәк ялгану әлеге алынмаларда авызның арткы өлешендә әйтелә торган тартык тәэсирендә соңгы иҗекнең сингармонизмда «калын иҗек» булып эшләвен, ягъни монысы да сүз азагындагы тартыкның сингармонизмда катнашуын аңлата.

Яңа (татарчалашмаган) рус алынмаларында да охшаш хәлләр күзәтелүе билгеле. Аларда да [и] сузыгы сингармонизмда нейтраль, һәм, нигездә, аларга калын кушымчалар ялгана: *илчелек советн**иг**-**ы*** [6: 904], *виски, суши* һ. б. Сүз азагындагы тартыкның сингармонизмда катнашуы да күзәтелә. Мәсәлән, йомшак тартыкка беткән сүзгә нечкә кушымчалар ялгана: *секрета**рь**-**лә**р, апре**ль**-**д**ә* [6: 905; 5: 12].

Рус һәм башка теллардән кергән иске (татарчалашкан) алынмаларда да, соңгы иҗектәге [и] сузыгының сүзгә кушымча ялгануга тәэсир итмәвен күрергә була. Мәсәлән, рус теленнән кергән *фатир* (< рус. *квартира*) һәм фин-угор телләреннән кергән *поши* сүзләренә калын кушымчалар ялгана (фатир: 100%, поши: 99,7%). Әлбәттә, әлеге сүзләрнең калын әйтелүен дә истән чыгармаска кирәк.

Бу тикшеренүдә без соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларындагы сингармонизм күренешләрен корпуста теркәлгән язма материаллардан файдаланып, күплек сан, тартым һәм килеш кушымчаларының калын яки нечкә булуына карап тикшердек.

Тикшеренү нәтиҗәләре шуны дәлилләде: 1) алынмаларның соңгы иҗегендәге [и] сузыгы сүзгә кушымчалар ялгануда артык зур роль уйнамый; 2) соңгыдан алдагы иҗектәге сузык һәм сүз азагындагы тартык исә кушымчаның калын яки нечкә варианты сайлануга тәэсир итә.

Киләчәктә башка кушымчаларны да исәпкә алып, әлеге күренешләрне, язма материаллар белән генә чикләнмичә, тулырак тикшерергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т I. 512 б.

2. Татар телендәге гарәп-фарсы алынмалары. URL: https://g-farsi.belem.ru/index.html (мөрәҗәгать итү көне: 05.04.2025)

3. Татар теленең язма корпусы. URL: https://search.corpus.tatar/tt (мөрәҗәгать итү көне: 26.07.2024)

4. Татар энциклопедиясе. URL: https://tatarica.org/tat/razdely/narody/tatary/tatarskij-yazyk/grammatika/singarmonizm (мөрәҗәгать итү көне: 26.07.2024)

5. *Burbiel, Gustav*. Tatar grammar. A Grammar of the Contemporary Tatar Literary Language. Stockholm/Moscow: Institute for Bible Translation, 2018. 901 p.

6. *Comrie, Bernard*. Tatar phonology. Alan S. Kaye (ed.) Phonologies of Asia and Africa 2. Winona Lake: Eisenbrauns. 1997. P. 899–911.

*Исследование проводилось при поддержке гранта научных исследований The Japan Society for the Promotion of Science (JSPS) 23KJ1014*

*Бу тикшерену the Japan Society for the Promotion of Science (JSPS) 23KJ1014 фәнни тикшеренүләр гранты ярдәмендә алып барылды*

*Рәхмәт сүзләре*

*Татар һәм рус телләрендәге текстларны – Казан федераль университеты доценты Рамил Йөзмөхәммәтов, инглиз һәм рус телләрендәгесен Зарина Фәйзиева редакцияләде. Аларга зур рәхмәтемне белдерәм.*

***Хисияма Юто,***
*Ниигата университеты ассистенты*

***Хисияма Юто,***
*ассистент Ниигатского университета*
*boltwatts@gmail.com*